**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 42 балл**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Трагедия жанрына хас үзенчәлекләрне Ф.Бурнашның “Таһир-Зөһрә” әсәре мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

2. Әсәрдәге Таһир белән Зөһрәгә бәйле вакыйгалар ничек тәмамлана? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (20 балл).**

1. Пенза өлкәсе Аккүл авылы – Казан – Орнебург – Ташкент. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).

3. К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә автор нинди сыйфатларны фаҗига итеп күтәрә? Санап чыгыгыз (4 балл).

4. Әлеге әсәрдә Исмәгыйль күргән төш символик мәгънәгә ия, аны әсәр сюжеты белән бәйләп аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

**III. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *усал, үзе, шикелле, матур, кебек, үзе, дә, сөйкемле, бер, үзе, түгел, үзе, болай, усал.*